КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 12 сентябрь г.Казань № 772

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары эшчәнлегендә мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдалану, мәгълүмат системаларын һәм мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасын планлаштыру, булдыру, үстерү, модернизацияләү, эксплуатацияләү чараларын координацияләү тәртибе турында» 2015 ел, 30 май, 387 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларының бердәм реестры турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары эшчәнлегендә мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдалану, мәгълүмат системаларын һәм мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасын планлаштыру, булдыру, үстерү, модернизацияләү, эксплуатацияләү чараларын координацияләү тәртибе турында» 2015 ел, 30 май, 387 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 12 октябрь, 740 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларының бердәм реестры турындагы нигезләмәгә, аны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына бер ай вакыт эчендә үз актларын бу карарга туры китерергә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына йөкләргә

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 30 май, 387 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 12 сентябрь, 772 нче
карары редакциясендә)

# Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларының бердәм реестры турында нигезләмә

1. Бу Нигезләмә «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре турында һәм мәгълүматны саклау хакында» 2006 ел, 27 июль, ФЗ-149 нчы Федераль закон, «Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» 2007 ел, 13 ноябрь, ТРЗ-58 нче Татарстан Республикасы Законы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларының бердәм реестрында мәгълүмат системаларын теркәү тәртибен һәм Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларының бердәм реестрын алып бару тәртибен билгеләүгә карата таләпләрне аныклый.

2. Бу Нигезләмәдә кулланыла торган терминнар:

мәгълүмат системасы – мәгълүмат һәм аны эшкәртүне тәэмин итүче мәгълүмат технологияләре җыелмасы;

Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларының бердәм реестры – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль бюджет исәбеннән һәм дәүләт бюджеттан тыш фондлар бюджеты исәбеннән төзелә һәм сатып алына торган мәгълүмат системаларын исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2012 ел, 26 июнь, 644 нче карары нигезендә эшләүче мәгълүмат системаларын исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасын файдаланып алып барыла торган, федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары нигезендә булдырылган мәгълүмат системаларын исәпкә алу реестры;

мәгълүмат системасы паспорты – электрон документ рәвешендә бирелгән мәгълүмат системасы турындагы мәгълүматларның структурлаштырылган җыелмасы;

Татарстан Республикасының бүленгән ситуацион үзәге – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган тәртиптә үзара хезмәттәшлек итүче, гомумкабул ителә торган мәгълүмат ресурслары һәм мәгълүмати-аналитик модельләр белән функциональ бәйсез, әмма әгълүмати бәйле булган ситуацион үзәкләр җыелмасы.

3. Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларының бердәм реестрын формалаштыру максатлары түбәндәгеләр булып тора:

Татарстан Республикасының бердәм мәгълүмати киңлеген булдыру;

Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системаларыннан файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру;

мәгълүмат системаларын булдыруга, эксплуатацияләүгә, эшләп бетерүгә бюджет чыгымнарын оптимальләштерү;

мәгълүмат системаларын кабатлауларга юл куймау һәм алардан файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру;

мәгълүмат системаларын һәм мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасы компонентларын булдыру, эксплуатацияләү, һәм эшләп бетерү принципларының барлык дәүләт идарәсе дәрәҗәләрендә бердәмлеген тәэмин итү;

функциональ бурычларны, аларны алып бару предметлары нигезендә хәл итү өчен Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлегендә мәгълүмат алмашуны тәэмин итү.

4. Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларының бердәм реестрында Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системалары, шулай ук Татарстан Республикасының бүленгән ситуацион үзәгендә кулланыла торган мәгълүмат системалары исәпкә алынырга тиеш.

5. Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларының бердәм реестрында мәгълүмат системаларын теркәү тәртибе мәгълүматлаштыру өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле башкарма органы тарафыннан билгеләнә һәм ул түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

мәгълүмат системасын теркәүгә тапшырыла торган документлар комплектының тасвирламасы, аларны таапшыру формасы һәм ысулы;

тапшырыла торган документларны, аларның карап тикшерү вакытларын, шулай ук документларны кабул итүдән баш тарту шартларын һәм (яки), тикшерү йомгаклары буенча уңай бәяләмә бирелгән очракта, мәгълүмат системасы теркәүгә алынуын күрсәтеп, кабул итүнең һәм тикшерүнең технологик барышы;

мәгълүмат системасына уникаль идентификация номерын бирү тәртибе;

корректлылык инициаторы белән мәгълүмат системасында бирелә торган уникаль идентификация номерын килештерү тәртибе;

мәгълүмат системасын теркәү яки мәгълүмат системасын теркәүдән нигезләнгән баш тарту турындагы раслый торган мәгълүматны инициаторга җибәрү формасы һәм ысулы.

6. Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларының бердәм реестрын алып бару тәртибе мәгълүматлаштыру өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле башкарма органы тарафыннан билгеләнә һәм түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

мәгълүмат системалары паспортларын актуальләштерү тәртибе;

файдаланучыларга Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларының бердәм реестрындагы үзгәрешләр турында мәгълүмат бирү тәртибе;

Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларының бердәм реестрыннан төшереп калдыру тәртибе;

Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларының бердәм реестрында урнаштырыла торган мәгълүматлар составы;

мәгълүмат системаларына ихтыяҗ булу турында мәгълүмат формалаштыру тәртибе;

башка кирәкле мәгълүмат.

---